ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«16» 03 2026 ел

№ 114

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри эшләр төрләрен һәм оешмалар һәм предприятиеләр исемлеген билгеләү турында»2025 елның 15 октябрендәге 340 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җинаять кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 299 статьясындагы беренче өлешенең 7.1 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» 2025 елның 23 июлендәге 218-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 219-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр өчен мәҗбүри эшләр төрләрен һәм оешмалар һәм предприятиеләр исемлеген билгеләү турында» 2025 елның 15 октябрендәге 340 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәр җәзасын үти ала торган предприятиеләр һәм оешмалар исемлеге» 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. "Мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәр җәзасын үти ала торган предприятиеләр һәм оешмалар исемлеге» 2 нче кушымтаны 1 нче кушымта дип санала.

1.3. «Территориядә җәзаны үтәү өчен мәҗбүри эш төрләре» 3 нче кушымтаны 2 нче кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе

М.В. Шеронов

ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның " ____" мартындагы ____ номерлы карарына 1 нче кушымта

Мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәр җәзасын үти ала торган предприятиеләр һәм оешмалар исемлеге

1. ТР Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитеты (ИНН 1637005626).
2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Антоновка авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005633).
3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005496).
4. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Бораково авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005489).
5. ТР Спас муниципаль районының Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637001396).
6. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005591).
7. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005471).
8. ТР Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005538).
9. ТР Спас муниципаль районының Ким авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005560).
10. Исполнительный комитет Кузнечихинского сельского поселения Спасского муниципального района РТ (ИНН 1637005601).
11. ТР Спас муниципаль районының Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637001491).
12. ТР Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005626).
13. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Приволжский авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005520).
14. ТР Спас муниципаль районының Урта Юрткүл авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005513).
15. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005577).
16. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005584).
17. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты (ИНН 1637005552).

ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның " ____" мартындагы ____ номерлы карарына 2 нче кушымта

ТР Спас муниципаль районы территориясендә җәза үтәү өчен мәҗбүри эш төрләре.

1. Җәмәгать урыннарын һәм территорияләрен төзекләндерү эшләре (чүп-чар җыю; кар җыю; яшелләндерү, үсемлек культураларын карау - чәчәк түтәлләрен, газоннарны, чәчәклекләрне утырту, утау, су сибү, агарту, агач һәм куаклар утырту, үсентеләрне кисү һәм җыю, үлән һәм корыган агачларны чабу; тротуарларны һәм мәйданнарны себерү, коелган яфракларны җыю).

2. Юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау, юл техникасы өчен мөмкин булмаган урыннарда юл өслеген пычрактан, чүп-чардан һәм кардан чистарту.

3. Күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрен, чердача һәм подвал урыннарын җыештыру;

4. Контейнер мәйданчыкларын чүп-чардан һәм каты көнкүреш калдыкларыннан санитар чистарту;

5. Юл буе полосасын төзекләндерү.

6. Тротуарларны, тротуар плиталарын чистарту, урамнарны себерү, тротуарлар һәм керү юллары салганда билгеле бер квалификация таләп ителми торган ярдәмче эшләр.